Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
16.12.2025 года №26

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы «Муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 14.02.2022 ел, №71 карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының “Җәлил шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы «Муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 14.02.2022 ел, №71 карарына (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 25.11.2022 ел, № 111, 22.02.2023 ел, № 130, №135 от 05.04.2023, № 151от 07.08.2023, №157 от 01.11.2023, №170 от 27.12.2023, №179 от 22.03.2024, №184 от 23.05.2024, №204 от 05.11.2024 ел, № 216 22.11.2024 ел, №233 06.02.2025 ел карарлары редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5 пунктның 2,3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем булу - вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен; югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына: муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы; муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Р.Ә.Кәримов